# Җырларыма тимәгез!

Рамил Чурагулов сүзләре

Фәнир Галимов көе




1

Беркемгә юк кырын эшем,
Көннән-көн көндәш арта.
Гади булсаң, кыен икән,
Дус дигән дә бер сата.

*Кушымта:*

Күзләремнән яшьләр тама,
"Гади җан бу" – димәгез.
Йөрәгемне телсәгез дә,
Җырларыма тимәгез.

2

"Ит изгелек – көт явызлык",
Дисәләр дә күп чагын.
Мин дә изгелекләр эшләп,
Алданам шул кайчагын.

3

Матур җырга тиң гомерләр
Узар изгелек кылып.
Дөнья фаный, бер китәрмен,
Җырларым калыр торып.

***Бетерү өчен:***

Изгелекләр эшлисем бар
Юлларымны бүлмәгез!